**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№511**
**01.02.2019**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Шәһәр мунчалары» МКП мөрәҗәгатен караганнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль Законның 17 маддәсендәге 1 пунктның 4 пунктчасы, Яр Чаллы шәһәре Уставының 28 маддәсендәге 1 пунктның 7 пунктчасы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакындагы нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр мунчалары» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган мунча хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында» 2017 елның 26 декабрендәге 8124 нче карары үз көчен югалткан дип таныпрга.
3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 1 февралендәге
511 нче карарына
кушымта

«Шәһәр мунчалары» МКП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| Т/с | Халык категориясе | 1 кешегә хезмәттән файдалану дәвамлылыгы | Тариф күләме, сум (өстәмә кыйммәткә салымнан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1. | Мунчаларның гомуми бүлегендә юыну: | | |
| - | Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, фашист концлагерьларының балигъ булмаган тоткыннары, «Блокадаланган Ленинградта яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар, Социалистик хезмәт Геройлары, СССР Геройлары | 1 сәгать 45 минут | түләүсез |
| - | Бөек Ватан сугышы инвалидлары | | |
| - | диализда торучы, сәламәтлекләре буенча инвалидлар | | |
| - | 7 яшькә кадәрге балалар | | |
| - | 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән (СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорын кертмичә) яисә Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән затлар | | 100,00 |
| - | һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннары | | |
| - | барлык категория пенсионерлар | | 150,00 |
| - | гражданнарның башка категорияләре | | 206,00 |
| 2. | Бассейннан файдалану: | | |
| - | гражданнарның барлык категорияләре өчен | 45 минут | 110,00 |
| - | барлык категория пенсионерлар | | 90,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова